ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ _______________ КАРАР _______________

с. Верхний Услон

Югары Ослан муниципаль районы буенча 2023 елга гомуми торак мәйданының бер квадрат метрының уртача бәясен раслау турында

Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы Министрлыгының «Россия Федерациясе буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метрының 2023 елның беренче яртыеллыгына бәясе нормативы һәм Россия Федерациясе субъектлары буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метрының 2023 елның I кварталына уртача базар хакы күрсәткечләре турында» 2023 елның 28 декабрендәге 1111/пр номерлы боерыгы нигезендә һәм «Татарстан Республикасы Бәяләүчеләр берлеге» НП Эксперт-консультация советының 2023 елның 26 март хаты белән, Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2023 елның I кварталына Югары Ослан муниципаль районы территориясендә гражданнарның торак шартларын яхшырту чараларын үткәрүгә социаль түләүләр күләме исәбеннән торак мәйданының бер квадрат метрының бәясен, «Торак» федераль максатчан программасының 2020-2025 елларга «Яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» программасын гамәлгә ашыру кысаларында авыл җирендә яшәүче, яшь гаиләләр һәм яшь белгечләрнең федераль бюджеты акчалары исәбеннән 58 754 сум тиен күләмендә расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары Черменский М.М. йөкләргә.

Башкарма комитеты җитәкчесе Р.А. Файрушин

Әзерләде һәм бастырды:
Бурдина Т.Н. 3 нөсхәдә